КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 18 август г.Казань № 619

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Архив эше турындагы законнарның үтәлешен төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 29 сентябрь, 928 нче карары белән расланган Архив эше турындагы законнарның үтәлешен төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Архив эше турындагы законнарның үтәлешен төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 29 сентябрь, 928 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 26 гыйнвар, 57 нче; 2022 ел, 20 май, 478 нче; 2023 ел, 18 июль, 854 нче; 2023 ел, 30 октябрь, 1366 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Архив эше турындагы законнарның үтәлешен төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 1.6 пункт өстәргә:

«1.6. Дәүләт архив комитеты тарафыннан нигезсез карарлар кабул итү һәм (яки) Дәүләт архив комитеты рәисе һәм аның урынбасары тарафыннан нигезсез гамәлләр кылу (гамәл кылмау), шул исәптән мәҗбүри таләпләр буенча ачыкланган бозуларны бетерү турында һәм (яки) мәҗбүри таләпләр буенча ачыкланган бозулар нәтиҗәләрен бетерү һәм (яки) мондый бозулар барлыкка килгәнгә кадәр булган хокукый хәлне торгызу буенча чаралар үткәрү хакында нигезсез күрсәтмәләр бирү рөхсәт ителми.»;

3.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Әгәр контроль объекты Дәүләт архив комитеты тарафыннан билгеле бер риск категориясенә кертелмәгән булса, ул түбән риск категориясенә кертелгән дип санала.

Дәүләт архив комитеты тарафыннан зыян (зарар) китерү рискларын бәяләү һәм алар белән идарә итү өчен кулланыла торган белешмәләрне даими мониторинглауны (җыю, эшкәртү, анализлау һәм исәпкә алуны) оештыру тәэмин ителә.

Контроль объектларын риск категорияләренә кертү яисә мәҗбүри таләпләрне бозу рискы индикаторларын билгеләү максатларында әлеге объектлар турында мәгълүмат җыю, аны эшкәртү, анализлау һәм исәпкә алу Дәүләт архив комитеты тарафыннан контрольдә тотылучы затлар белән хезмәттәшлек итмичә (мәҗбүри профилактик визит кысаларында мәгълүмат җыю, аны эшкәртү, анализлау һәм исәпкә алудан тыш) башкарыла. Контроль объектларын риск категорияләренә кертү яисә мәҗбүри таләпләрне бозу рискы индикаторларын билгеләү максатларында әлеге объектлар турында мәгълүмат җыю, аны эшкәртү, анализлау һәм исәпкә алуны гамәлгә ашырганда контрольдә тотылучы затларга федераль законнарда каралмаган өстәмә бурычлар йөкләнә алмый.»;

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Шактый, урта, уртача һәм түбән риск категорияләренә кертелгән юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә карата планлы тикшерүләр үткәрү гамәлгә ашырылмый.»;

4.2 пунктта татар текстында «гамәлгә ашырыла» сүзләре алдына «Контроль төрләренең бердәм реестрына белешмәләр кертү юлы белән» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 5.2 пункт өстәргә:

«5.2. Профилактик чаралар уздырганда Дәүләт архив комитеты гражданнар, оешмалар белән «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән очракларда гына үзара хезмәттәшлек итә. Әгәр башкасы «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнмәгән булса, контрольдә тотылучы затлар белән үзара хезмәттәшлек ителә торган профилактик чаралар әлеге контрольдә тотылучы затларның ризалыгы яки аларның инициативасы белән генә үткәрелә.»;

түбәндәге эчтәлекле 5.3 пункт өстәргә:

«5.3. Әгәр дә профилактик чаралар үткәргәндә контроль объектларының закон белән саклана торган кыйммәтләргә турыдан-туры ачык зыян (зарар) китерү куркынычын тудыруы яки андый зыян (зарар) китергәне билгеләнсә, Дәүләт архив комитетының вазыйфаи заты контроль (күзәтчелек) чараларын уздыру турында карар кабул итү өчен бу турыда Дәүләт архив комитеты рәисенә (рәис урынбасарына) кичекмәстән мәгълүмат җибәрә яисә «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясында күрсәтелгән чараларны кабул итә.»;

7.1 пунктта «төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру нәтиҗәләре бирелгән доклад (алга таба – хокук куллану практикасы турында доклад) әзерли» сүзләрен «Дәүләт архив комитетының хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләре бирелгән доклад (алга таба – хокук куллану практикасы турында доклад) әзерли һәм хокук куллану практикасы турында доклад проекты буенча ачык фикер алышуны тәэмин итә» сүзләренә алмаштырырга;

8.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.4. Мәҗбүри таләпләр бозу рөхсәт ителмәү турында кисәтү контрольдә тотылучы затка «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә белдерелә һәм җибәрелә, һәм анда норматив хокукый актта карала торган тиешле мәҗбүри таләпләргә күрсәтмә, контрольдә тотылучы затның мәҗбүри таләпләрне бозуга китерергә мөмкин булган яисә китерә алган билгеле бер гамәлләр кылуы (гамәл кылмавы) турында мәгълүмат, шулай ук әлеге таләпләрнең үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрү турында тәкъдим бирелергә тиеш һәм контрольдә тотылучы зат тарафыннан белешмәләр һәм документлар тапшыру таләбе, контрольдә тотылучы затның мәҗбүри таләпләрне бозуга китерә яисә китерә торган гамәлләре (гамәл кылмавы) нәтиҗәсендә барлыкка килгән нәтиҗәләрне бетерү сроклары була алмый.»;

9.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Контрольдә тотылучы зат Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталы яки дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр төбәк порталы аша консультация үткәрү турында гариза бирә.»;

X бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«X. Профилактик визит

10.1. Профилактик визит Дәүләт архив комитетының вазыйфаи заты тарафыннан, контрольдә тотылучы затның эшчәнлек алып бару урыны буенча яисә видеоконференция элемтәсе яисә «Инспектор» мобиль кушымтасын кулланып, профилактик әңгәмә формасында уздырыла.

10.2. Профилактик визит барышында контрольдә тотылучы затка аның эшчәнлегенә яисә аңа караган контроль объектларына карата куелган мәҗбүри таләпләр, аларның риск критерийларына туры килүе, риск категориясен киметү буенча тәкъдим ителгән ысуллар, төрләр, аларны карап тоту һәм контроль объектына карата аны тиешле риск категориясенә кертүдән чыгып үткәрелә торган чараларның интенсивлыгы турында мәгълүмат бирелә.

10.3. Профилактик визит барышында Дәүләт архив комитетының вазыйфаи заты контроль объекты белән танышуны, контроль объектларын риск категорияләренә кертү өчен кирәкле мәгълүмат җыюны гамәлгә ашыра һәм контрольдә тотылучы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлү дәрәҗәсен бәяли.

10.4. Профилактик визит контроль (күзәтчелек) органы инициативасы буенча (мәҗбүри профилактик визит) яки контрольдә тотылучы зат инициативасы буенча үткәрелә.

10.5. Мәҗбүри профилактик визит үткәрү турында мәгълүмат Дәүләт архив комитеты тарафыннан контрольдә тотылучы затларга «Россия Федерациясендә

дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге № 248-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясындагы 4 һәм 5 өлешләрендә билгеләнгән тәртиптә җиткерелә.

10.6. Мәҗбүри профилактик визитлар үткәрелә:

1) контрольдә тотылучы затларга, аларның шактый, урта, уртача риск категориясенә кертелгән контроль объектларына карата Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тикшерү вакытларында;

2) Россия Федерациясе Президенты кушуы буенча;

3) Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе яки Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасары – Россия Федерациясе Хөкүмәте Аппараты Җитәкчесе белән килештерелгән Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасары кушуы буенча;

4) Татарстан Республикасы Рәисе кушуы буенча.

10.7. Мәҗбүри профилактик визит контрольдә тотылган затның аны үткәрүдән баш тартуын күздә тотмый.

10.8. Мәҗбүри профилактик визит кысаларында Дәүләт архив комитетының вазыйфаи заты, кирәк булганда, тикшерү үткәрә, кирәкле документларны соратып ала.

10.9. Мәҗбүри профилактик визит үткәрү срогы 10 эш көненнән артмаска тиеш.

10.10. Мәҗбүри профилактик визит үткәрү тәмамланганнан соң, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясында каралган тәртиптә мәҗбүри профилактик визит уздыру турында акт (алга таба шул ук эзлеклелектә – мәҗбүри профилактик визит акты) төзелә.

10.11. Контрольдә тотылучы зат яисә аның вәкиле мәҗбүри профилактик визит актының эчтәлеге белән «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 88 статьясында каралган тәртиптә таныша.

10.12. Мәҗбүри профилактик визит уздыру мөмкинлеге булмаган һәм (яисә) контрольдә тотылучы зат аны уздырудан читләшкән очракта, Дәүләт архив комитетының вазыйфаи заты тарафыннан «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 65 статьясындагы 10 өлешендә каралган тәртиптә мәҗбүри профилактик визит үткәрү мөмкинлеге булмау турында акт төзелә.

10.13. Мәҗбүри профилактик визит уздыру мөмкин булмаган очракта, Дәүләт архив комитетының вәкаләтле вазыйфаи заты, мәҗбүри профилактик визит уздыру мөмкинлеге булмау турында акт төзелгән көннән алып өч айдан да соңга калмыйча, контрольдә тотылучы затка карата мәҗбүри профилактик визитны кабат уздыру турында карар кабул итәргә хокуклы.

10.14. Ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмә, әгәр мондый бозулар мәҗбүри профилактик визит уздыру тәмамланганга кадәр «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның $90^1$ статьясында каралган тәртиптә бетерелмәгән очракта, контрольдә тотылучы

затка бирелә.

10.15. Контрольдә тотылучы затның инициативасы буенча профилактик визит аның гаризасы нигезендә, әгәр дә бу зат кече эшмәкәрлек субъектларына караса, социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма яисә дәүләт яки муниципаль учреждение булып торса, үткәрелергә мөмкин.

10.16. Контрольдә тотылучы зат Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталы яки дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр төбәк порталы аша профилактик визит үткәрү турында гариза (алга таба – гариза) бирә. Дәүләт архив комитеты гаризаны 10 эш көне эчендә карый һәм профилактик визит үткәрү яки аны үткәрүдән баш тарту турында карар кабул итә, бу хакта контрольдә тотылучы затка хәбәр итә.

10.17. Профилактик визит үткәрү турында карар кабул ителгән очракта, Дәүләт архив комитеты 20 эш көне эчендә аның үткәрү датасын контрольдә тотылучы зат белән теләсә нинди ысул белән килештерә, әлеге килештерүнең теркәлүен тәэмин итә.

10.18. Профилактик визит үткәрүдән баш тарту турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) контрольдә тотылучы заттан гаризаны кире алу турында хәбәрнамә кергәндә;

2) кабат гариза биргән көнгә кадәр алты ай эчендә профилактик визит уздыру контрольдә тотылучы затның эшчәнлекне гамәлгә ашыру урынында булмавына йә контрольдә тотылучы затның профилактик визит үткәрүнең мөмкин булмавына китергән башка гамәлләренә (гамәл кылмавына) бәйле рәвештә мөмкин булмаганда;

3) гариза бирү датасына кадәр ел дәвамында контроль (күзәтчелек) орган тарафыннан алдан бирелгән гариза буенча профилактик визит уздырганда;

4) гаризада әдәпсез яисә мыскыллы сүзләр булганда, контроль (күзәтчелек) органының вазыйфаи затлары яисә аларның гаилә әгъзалары тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә куркыныч янаганда.

10.19. Профилактик визит үткәрүдән баш тарту турында карар контрольдә тотылучы зат тарафыннан «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтү) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 39 – 43 статьяларында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

10.20. Контрольдә тотылучы зат гаризаны кире алырга йә, профилактик визит уздыру датасына кадәр биш эш көненнән дә соңга калмыйча, Дәүләт архив комитетына хәбәр итеп, профилактик визит үткәрүдән баш тарту кәгазе җибәрергә хокуклы.

10.21. Профилактик визит барышында контрольдә тотылучы зат тарафыннан алынган аңлатмалар һәм тәкъдимнамәләр тәкъдим итү характерына ия.

10.22. Профилактик визит барышында ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бетерү турында күрсәтмәләр контрольдә тотылучы затларга бирелмәскә мөмкин.

10.23. Әгәр профилактик тикшерү уздырганда контроль объектлары закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычы булса яисә мондый зыян (зарар) китерсә, Дәүләт архив комитетының вазыйфаи заты контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрү турында карар кабул итү өчен бу хакта Дәүләт архив комитеты рәисенә (рәис урынбасарына) кичекмәстән мәгълүмат

җибәрә.»;

XI бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«XI. Дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру

11.1. Архив эше турындагы законнарның үтәлешенә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) планнан тыш контроль (күзәтчелек) чаралары уздырып гамәлгә ашырыла.

11.2. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда, контроль объектының риск категориясен исәпкә алып, контроль (күзәтчелек) чараларының түбәндәге төрләре үткәрелә:

документар тикшерү;

күчмә тикшерү.

11.3. Контроль (күзәтчелек) чаралары планнан тыш нигездә Дәүләт архив комитетының вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 76, 79, 80 статьяларында билгеләнгән түбәндәге контроль (күзәтчелек) гамәлләрен башкару юлы белән генә уздырылырга мөмкин:

карау;

язма аңлатмалар алу;

документларны таләп итеп сорап алу.

11.4. Планнан тыш контроль (күзәтчелек) чаралары түбәндәге нигезләр булганда үткәрелә:

Дәүләт архив комитетында, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроле турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 60 статьясындагы 1 өлешенең 4 пункты нигезләмәсен исәпкә алып, закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү турында яисә зыян (зарар) китерү куркынычы хакында белешмәләр булу;

билгеле бер контрольдә тотылучы затларга карата контроль (күзәтчелек) чаралары уздыру турында Россия Федерациясе Президенты йөкләмәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәсе;

прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешенә, кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең үтәлешенә күзәтчелек итү кысаларында контроль (күзәтчелек) чарасы үткәрү турында прокурор таләбе;

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 95 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән очракларда – Дәүләт архив комитетының мәҗбүри таләпләр буенча ачыкланган бозуларны бетерү турында карарын үтәү срогы чыгу;

контроль объектының мәҗбүри таләпләрне бозу рискыы индикаторлары белән расланган параметрларга туры килүен ачыклау яки контроль объектының шундый параметрлардан тайпылуы;

контрольдә тотылучы затның мәҗбүри профилактик визит уздырудан читләшүе.

Әгәр планнан тыш контроль (күзәтчелек) чарасы прокуратура органнары белән килештерелгәннән соң гына уздырылырга мөмкин булса, әлеге чара мондый килештерелгәннән соң уздырыла.

11.5. Контроль (күзәтчелек) чарасын уздыру өчен Дәүләт архив комитеты рәисе яисә аның урынбасары тарафыннан имзаланган Дәүләт архив комитеты карары кабул ителә.

Контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү турындагы карарда «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 64 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән белешмәләр, шулай ук төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда үтәлеше бәяләнә торган мәҗбүри таләпләр бирелгән норматив хокукый актлар исемлеге күрсәтелә.

11.6. Контрольдә тотылучы затка Дәүләт архив комитетының вазыйфаи заты тарафыннан, контроль (күзәтчелек) чарасы башланганга кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча, контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү турында «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтүе) һәм муниципаль контроле турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясының 4 һәм 5 өлешләрендә билгеләнгән тәртиптә хәбәр ителә.

11.7. Контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү барышында контроль (күзәтчелек) чаралары предметында күрсәтелгән, мәҗбүри таләпләр куела торган контроль объектларына карата мәҗбүри таләпләрнең үтәлеше бәяләнә.

11.8. Төбәк дәүләт контроле (күзәтүчелеге) кысаларында контроль (күзәтчелек) чарасы турында мәгълүмат Контроль (күзәтчелек) чаралары бердәм реестрына урнаштырыла.

11.9. Контрольдә тотылучы зат белән үзара хезмәттәшлекне күздә тота торган контроль (күзәтчелек) чарасы Контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрына аны булдыру һәм алып бару кагыйдәләрендә билгеләнгән белешмәләр кертелгәннән соң (реестр операторы тарафыннан теркәлгән контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестры эшләмәү очракларыннан тыш) башланырга мөмкин.

11.10. Дәүләт архив комитеты, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтүчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 60 статьясындагы 1 өлешендә каралган белешмәләр кергәндә һәм мәҗбүри таләпләр бозуларны булдырмау һәм бетерү өчен кичектергесез чаралар кабул итәргә кирәк булганда, планнан тыш контроль (күзәтчелек) чарасын кичекмәстән (әлеге белешмәләр алынганнан соң 24 сәгать эчендә) үткәрүгә керешә, бу хакта контроль объектының урнашу урыны буенча прокуратура органына шул ук срок эчендә планнан тыш контроль (күзәтчелек) чарасы турында белешмәләр, планнан тыш контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү турында карар күчермәсен һәм аны үткәрүгә нигез булган белешмәләр бирелгән документлар җибәрү юлы белән хәбәр итә. Бу очракта контрольдә тотылучы затка планнан тыш контроль (күзәтчелек) чарасы уздыру турында хәбәр ителмәскә мөмкин.»;

12.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12.1. Документар тикшерү дигәндә Дәүләт архив комитеты урнашкан урында үткәрелә торган контроль (күзәтчелек) чарасы аңлашыла, аның предметы бары тик контрольдә тотылучы затларның оештыру-хокукый рәвешен, хокукларын һәм бурычларын билгели торган документларындагы белешмәләрдән, шулай ук аларның эшчәнлеген гамәлгә ашырганда кулланыла торган һәм аларның Дәүләт архив комитетының мәҗбүри таләпләрен һәм карарларын үтәвенә бәйле документлардан гыйбарәт.

Документар тикшерү барышында контрольдә тотылучы затларның Дәүләт архив комитеты карамагындагы документлары, элеккеге контроль (күзәтчелек) чаралары нәтиҗәләре, административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау материаллары һәм шушы контрольдә тотылучы затларга карата гамәлгә ашырылган дәүләт контроле (күзәтчелеге) нәтиҗәләре турындагы башка документлар карала.»;

12.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Дәүләт архив комитеты тарафыннан контрольдә тотылучы затка документар тикшерү барышында карау өчен кирәкле документларны кертү таләбе алынган вакыттан Дәүләт архив комитетына таләптә күрсәтелгән документлар тапшырылган вакытка кадәр, шулай ук контрольдә тотылучы затка Дәүләт архив комитеты тарафыннан тапшырылган документлардагы хаталарны һәм (яисә) каршылыкларны ачыклау турында йә бу документлардагы белешмәләрнең Дәүләт архив комитетының документларындагы һәм (яки) дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда алынган белешмәләргә туры килмәве турында мәгълүмат һәм кирәкле язма аңлатмаларны бирү таләпләре җибәрелгән вакыттан кирәкле язма аңлатмалар Дәүләт архив комитетына бирелгәнгә кадәр документар тикшерү үткәрү срогын исәпләү туктатып торыла.»;

түбәндәге эчтәлекле 12.5 – 12.8 пунктлар өстәргә:

«12.5. Дәүләт архив комитеты карамагындагы документларда бирелгән белешмәләрнең дөреслеге нигезле шик тудырса яисә бу белешмәләр контрольдә тотылучы затның мәҗбүри таләпләрне үтәвен бәяләргә мөмкинлек бирмәсә, Дәүләт архив комитеты контрольдә тотылучы зат адресына документар тикшерү барышында карап тикшерү өчен кирәкле башка документларны тапшыруга таләп җибәрә. Әлеге таләп алынган көннән алып 10 эш көне эчендә контрольдә тотылучы зат Дәүләт архив комитетына таләптә күрсәтелгән документларны җибәрергә тиеш.

12.6. Әгәр документар тикшерү барышында контрольдә тотылучы зат тарафыннан бирелгән документларда хаталар һәм (яисә) каршылыклар ачыкланган яисә әлеге документлардагы белешмәләрнең Дәүләт архив комитетында булган һәм (яки) дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда алынган белешмәләргә туры килмәве ачыкланган булса, хаталар, каршылыклар һәм белешмәләрнең туры килмәве турында мәгълүмат контрольдә тотылучы затка 10 эш көне эчендә кирәкле язма аңлатмалар бирү таләбе җибәрелә. Тапшырылган документларда ачыкланган хаталарга һәм (яисә) каршылыкларга карата яисә әлеге документлардагы белешмәләрнең Дәүләт архив комитетында булган һәм (яки) дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда алынган белешмәләргә туры килмәвенә карата язма аңлатмалар бирә торган контрольдә тотылучы зат Дәүләт архив комитетына элек тапшырылган документларның дөреслеген раслый торган документларны

өстәмә рәвештә бирергә хокуклы.

12.7. Документар тикшерү уздырганда Дәүләт архив комитеты контрольдә тотылучы заттан документар тикшерү предметына карамаган белешмәләрне һәм документларны, шулай ук Дәүләт архив комитеты тарафыннан башка органнардан алынырга мөмкин булган белешмәләрне һәм документларны таләп итәргә хокуксыз.

12.8. Планнан тыш документар тикшерү прокуратура органнары белән килештерелеп кенә («Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4, 6 пунктлары нигезендә үткәрү очрагыннан тыш) үткәрелергә мөмкин.»;

XIII бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«XIII. Күчмә тикшерү

13.1. Күчмә тикшерү дигәндә бина, бүлмә, корылма, җиһаз һәм материалларның хуҗасы булган яисә алардан файдалана торган билгеле бер контрольдә тотылучы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлүен бәяләү, шулай ук Дәүләт архив комитеты карарлары башкарылуын бәяләү максатларында әлеге контрольдә тотылучы зат белән үзара хезмәттәшлек итеп үткәрелә торган комплекслы контроль (күзәтчелек) чарасы аңлашыла.

13.2. Күчмә тикшерү контрольдә тотылучы затның яисә контроль объектының урнашу урыны буенча уздырыла.

13.3. Күчмә тикшерү түбәндәгеләр мөмкин булмаган очракта үткәрелә:

1) Контрольдә тотылучы затның Дәүләт архив комитеты карамагындагы яисә ул соратып ала торган документларында һәм аңлатмаларында булган белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген тикшерергә;

2) контрольдә тотылучы затның эшчәнлеге, гамәлләре (гамәл кылмавы) һәм (яисә) аныкы булган һәм (яисә) аның тарафыннан файдаланыла торган контроль объектларының мәҗбүри таләпләргә туры килүен 13.2 пунктта күрсәтелгән урынга бармыйча һәм контроль (күзәтчелек) чараларының башка төре кысаларында каралган кирәкле контроль (күзәтчелек) гамәлләрен башкармыйча бәяләргә.

13.4. Күчмә тикшерү үткәрү турында мәгълүмат контрольдә тотылучы затка, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясында каралган тәртиптә күчмә тикшерү башланганга кадәр 24 сәгатьтән дә соңга калмыйча, аңа күчмә тикшерү үткәрү турында карар күчермәсен җибәрү юлы белән хәбәр ителә.

Күчмә тикшерү барышында түбәндәге контроль (күзәтчелек) гамәлләре башкарылырга мөмкин:

карау;

сораштыру;

язма аңлатмалар алу;

документларны таләп итеп сорап алу.

13.6. Күчмә тикшерүне үткәрү срогы 10 эш көненнән артып китә алмый.

Күчмә тикшерүне үткәрү барышында кече эшмәкәрлекнең бер субъектына

карата үзара хезмәттәшлекнең гомуми срогы кече предприятие өчен 50 сәгатьтән һәм микропредприятие өчен 15 сәгатьтән арта алмый.

Россия Федерациясенең берничә субъекты территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмага карата күчмә тикшерү үткәрү срогы оешманың һәр филиалы, вәкиллеге, аерымланган структур бүлекчәсе яисә җитештерү объекты буенча аерым билгеләнә.

13.7. Контроль (күзәтчелек) чарасын уздыручы Дәүләт архив комитетының вәкаләтле вазыйфаи затлары һәм контроль (күзәтчелек) чараларын уздыруга җәлеп ителүче затлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозу дәлилләре теркәлү өчен фотога төшерү, аудио һәм видеоязма файдаланылырга, шәхси компьютерлар, алына торган электрон мәгълүмат чыганаклары, күчермә алу аппаратлары, сканерлар, телефоннар (шул исәптән кәрәзле элемтә), механик һәм электрон үлчәү чаралары, дәлилләрне теркәү өчен башка ысуллар (алга таба – техник чаралар) кулланылырга мөмкин.

Контроль (күзәтү) чараларын үткәргәндә техник чаралар куллану турында карар контроль (күзәтү) чарасын үткәрүче вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан мөстәкыйль кабул ителә.

Фотога төшерү, аудиога һәм видеога яздыру контрольдә тотылучы затка мәҗбүри хәбәр итеп башкарыла.

Фотога төшерү юлы белән мәҗбүри таләпләр бозуларны теркәү мәҗбүри таләпләрнең ачыкланган һәр бозуларын кимендә ике тапкыр фоторәсемгә төшереп гамәлгә ашырыла.

Аудиога һәм видеога яздыру контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү барышында язманы гамәлгә ашыруның датасы, урыны, яздыра башлау һәм яздыруны тәмамлау вакыты турында язманың башында һәм ахырында өзлексез хәбәр итеп башкарыла. Яздыру барышында ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозу урыны һәм характеры җентекләп теркәлә һәм күрсәтелә.

Мәҗбүри таләпләрне бозу дәлилләрен теркәү өчен фотога төшерүдән һәм видеога яздырудан файдалану дәүләт серен саклау турында Россия Федерациясе законы таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Техник чараларны куллану нәтиҗәләре контроль (күзәтчелек) чарасы актына кушымта итеп рәсмиләштерелә.

13.8. Әгәр контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү контрольдә тотылучы затның урнашу (эшчәнлекне гамәлгә ашыру) урыны буенча булмавы яисә контрольдә тотылучы зат тарафыннан эшчәнлекнең фактта булмауга бәйле рәвештә яисә контрольдә тотылучы затның контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү яисә тәмамлау мөмкин булмауга китергән башка гамәлләренә (гамәл кылмавына) бәйле рәвештә мөмкин булмаган булса, Дәүләт архив комитетының вазыйфаи заты, сәбәпләрен күрсәтеп, контрольдә тотылучы зат белән үзара хезмәттәшлекне күздә тота торган контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрүнең мөмкин булмавы турында акт төзи һәм контрольдә тотылучы затка «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясындагы 4 һәм 5 өлешләрендә каралган тәртиптә контрольдә тотылучы зат белән үзара хезмәттәшлекне күздә тота торган контроль (күзәтчелек) чарасын уздыру мөмкинлеге булмау турында хәбәр итә. Бу очракта

Дәүләт архив комитетының вазыйфаи заты контрольдә тотылучы зат белән үзара хезмәттәшлек итүне күздә тота торган контроль (күзәтчелек) чарасын уздыру тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта әлеге контроль (күзәтчелек) чарасы кысаларында контроль (күзәтчелек) гамәлләрен башкарырга хокуклы.

13.9. Әлеге Нигезләмәнең 13.8 пунктында күрсәтелгән очракта, Дәүләт архив комитетының вәкаләтле вазыйфаи заты, контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү мөмкинлеге булмау турында акт төзелгән көннән алып өч айдан да соңга калмыйча, контрольдә тотылучы затка алдан хәбәр итмичә һәм прокуратура органнары белән килештермичә, шундый ук контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү турында карар кабул итәргә хокуклы.

13.10. Контрольдә тотылучы затның контроль (күзәтчелек) чарасын уздырудан баш тартуы яисә аны үткәрүгә каршылык күрсәтүе Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән җаваплылыкка тарта.

13.11. Планнан тыш күчмә тикшерү прокуратура органнары белән килештереп кенә («Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4, 6 пунктлары, 3 өлеше һәм 66 статьясындагы 12 өлеше нигезендә үткәрү очракларыннан тыш) үткәрелергә мөмкин.»;

14.1 пунктта «248-ФЗ номерлы» сүзләрен «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

14.2 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

15.1 пунктта «248-ФЗ номерлы» сүзләрен «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

15.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15.7. Хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре, алар фикеренчә, архив эше турындагы законнарның үтәлешенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру кысаларында турыдан-туры бозылган контрольдә тотылучы затлар түбәндәгеләргә карата судка кадәр шикаять бирергә хокуклы:

1) контроль (күзәтчелек) чараларын һәм мәҗбүри профилактик визитларны үткәрү турында карарларга;

2) контроль (күзәтчелек) чаралары һәм мәҗбүри профилактик визитлар актларына, ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәләргә;

3) контроль (күзәтчелек) чаралары һәм мәҗбүри профилактик визитлар кысаларында Дәүләт архив комитетының вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына);

4) контроль объектларын тиешле риск категориясенә кертү турында карарларга;

5) контрольдә тотылучы затларның гаризалары буенча мәҗбүри профилактик визитлар үткәрүдән баш тарту турында карарларга;

6) контрольдә тотылучы затларга яки контроль объектларына карата «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законда каралган профилактик

һәм (яисә) контроль (күзәтчелек) чаралары йомгаклары буенча Дәүләт архив комитеты тарафыннан кабул ителә торган башка карарларга.»;

15.15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15.15. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

Дәүләт архив комитетының исеме;

карарларына һәм (яки) гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме;

гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), яшәү урыны (эшчәнлекне башкару урыны) турында белешмәләр, яисә гариза бирүче оешманың исеме, бу оешманың урнашу урыны турында белешмәләр, яисә ышанычнамә реквизитлары һәм ышанычнамә буенча шикаять бирүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), шикаятьне карау вакытына үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру өчен теләгән ысул һәм аның буенча карар алу өчен теләгән ысул;

Дәүләт архив комитеты вазыйфаи затының шикаять биргән контрольдә тотылучы зат хокукларын бозуга китергән яисә китерергә мөмкин булган, шикаять бирелә торган карары һәм (яисә) гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

гариза бирүче Дәүләт архив комитетының вазыйфаи заты карары һәм (яисә) гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәгән нигезләр һәм дәлилләр. Шикаять бирүче зат тарафыннан аның дәлилләрен раслый торган документлар (булганда) яисә аларның күчермәләре бирелергә мөмкин;

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 4 өлешенең 1 – 3 өлешендә каралган нигезләр буенча шикаять бирелгән очракта, Контроль (күзәтчелек) чаралары бердәм реестрында контроль (күзәтчелек) чараларының яисә мәҗбүри профилактик визитның исәпкә кую номеры;

Контроль төрләре бердәм реестрында контроль объектының исәпкә кую номеры (контроль объектын тиешле риск категориясенә кертү турында карарга шикаять бирелгән очракта);

шикаять биргән затның таләпләре.

Шикаятьтә Дәүләт архив комитетының вазыйфаи затларына йә аларның гаилә әгъзаларына карата әдәпсез һәм мыскыллы сүзләр, аларның тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар булмаска тиеш.»;

15.18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15.18. Шикаять Дәүләт архив комитеты тарафыннан судка кадәр шикаять бирүнең ярдәмче системасында теркәлгән көннән алып 15 эш көне эчендә каралырга тиеш.

Контрольдә тотылучы затның контроль объектларын тиешле риск категориясенә кертү турындагы карарга карата шикаяте иң күбе биш эш көне эчендә карап тикшерелә.

Дәүләт архив комитеты шикаять биргән контрольдә тотылучы заттан шикаять предметына кагылышлы өстәмә мәгълүмат һәм документлар сорарга хокуклы.

Контрольдә тотылучы зат әлеге мәгълүматны һәм документларны рәсми сорау җибәрелгән көннән алып биш эш көне эчендә тапшырырга хокуклы. Шикаятьне карап тикшерү срогы дәвамы шикаять предметына карый торган өстәмә

документлар һәм мәгълүмат бирү турында рәсми сорау җибәрелгән көннән алып аларны Дәүләт архив комитеты алган көнгә кадәр, әмма рәсми сорау җибәрелгән көннән алып иң күбе биш эш көненә кадәр туктатып торыла. Контрольдә тотылучы заттан шикаять предметына карый торган өстәмә документлар һәм мәгълүмат алынмау шикаятьне караудан баш тарту өчен нигез булып тормый.»;

15.19 пунктта:

беренче абзацта татар текстында «Дәүләт архив комитеты» сүзләреннән соң «һәм башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә аларның ведомство буйсынуындагы оешмалар» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт архив комитетының кабул ителгән карар нигезләве, аны үтәү срогы һәм тәртибе бирелгән карары, әлеге карар кабул ителгән көннән алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча, контрольдә тотылучы затның Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталындагы шәхси кабинетында урнаштырыла.»;

16.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Дәүләт архив комитеты ел саен контроль төре турында доклад әзерли, анда төп күрсәткечләргә ирешү турында белешмәләр һәм контроль төрләренең индикатив күрсәткечләре турында, шул исптән профилактик чараларның һәм контроль (күзәтчелек) чараларының төп күрсәткечләргә ирешүгә йогынтысы турында белешмәләр, шулай ук хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләре буенча тәкъдимнәр күрсәтелә.»;

17.1 пунктның 1 пунктчасында «мәҗбүри таләпләр (куркынычсызлык мониторингы) үтәлешен күзәтү нәтиҗәләре буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 17.2 пункт өстәргә:

«17.2. Контроль объектының мәҗбүри таләпләрне бозу рискы индикаторлары белән расланган параметрларга туры килүе яки контроль объектының шундый параметрлардан тайпылуы ачыкланганда, Дәүләт архив комитетының вазыйфаи заты Дәүләт архивы комитетының вәкаләтле вазыйфаи затына контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү турында мотивлаштырылган күрсәтмә җибәрә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Эл.Хөк., А.М.Сәгыйтова